**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2021елның 29 ноябре** **93-РС номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегенең генераль планы проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 20021 елның 21 июлендәге 10-53/9275 номерлы бәяләмәсен, 2021 елның 12 августындагы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен һәм искәрмәләрне җайга салу буенча Килештерү комиссиясенең 20021 елның 1 октябрендәге беркетмәсен карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең генераль планы проектын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үз көченә кергән вакыттан «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2018 елның 01 октябрендәге 57-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**